**Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән олимпиада биремнәренең ҖАВАПЛАРЫ**
**2025-2026 нчы уку елы**
**5 нче сыйныф**

**Максималь балл – 58**

## I. ТЕСТ (20 балл)

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **1** | **2** | **4** | **3** | **2** | **3** | **3** | **3** | **2** | **3** |

## II. Теоретик бирем.

Шигырьне укыгыз. Аерып бирелгән 1 зат берлек сандагы фигыльләрнең тиешле кушымчаларын языгыз. Хикәя фигыль турында белгәннәрегезне языгыз. (**10 балл) 4+ 6**

Фәннәр **укый**м мәктәбемдә –
Тырышып белем **алам**.
Туган телемне яратам,
Тукайны укып **беләм**.
Беләсегез килсә, быел
Мин бишенчегә керәм.
Алдымда күпме мәсьәлә
Җавабын үзем чишәм.
Йолдызлар серен ачарга
**Чакыра** мине җиһан.

Укучы хикәя фигыль турында мәктәп программасы, дәреслекләрдә бирелгән материалны мөмкин кадәр тулы чагылдырган очракта, биремгә иң югары балл **(6)** куела. Төгәлсезлекләрнең күләменә карап, баллар саны киметелә. Мәгълүмат бөтенләй булмаган очракта, укучыга 0 балл куела.

## III.Уйлагыз һәм җавапларны языгыз.

Бирелгән сүзләргә берәр хәреф өстәп, тамырдаш сүз ясагыз, ул сүзләрне языгыз. **(5 балл)**

Тара- - тарак
Бизә- - бизәк
Аш - аша
Илә- иләк
Ела- - елак

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Фразеологик әйтелмә һәм аның мәгънәсен тәңгәлләштерегез, җавапны саннар белән языгыз. **(5 балл)**

| | |
|---|---|
| А) трай тибү | 1) ачулану |
| Ә) авызы колакка җитү | 2) эшләмәү |
| Б) пыр туздыру | 3) курку |
| В) күз буяу | 4) алдау |
| Г) хафага төшү | 5) шатлану |

**Җавап : ______25143_________________**

2. Шигырьне укыгыз һәм күп нокталар урынына тиешле хәрефләрне куегыз. **(4 балл)**

Алланып таңнарның алына,
Нур булып кешелек таңына,
Җыр булып үрелеп kү**ң**елгә,
Кил безгә, Яңа ел, кил безгә!
Ко**я**шлы көннәрнең җылысын,
Бәхетнең, шатлыкның ол**ы**сын
Күтәреп көннәрнең и**ң**енә,
Рәхим ит Туган ил түренә! (*Э. Мөэминова*)

3. *Кояшлы көннәрнең җылысын* юлындагы сүзләрне антонимнарына үзгәртеп языгыз. **(3 балл)**

**Болытлы төннәрнең салкынын**

---

4. Беренче куплеттан тамырдаш сүзләрне күчереп алыгыз, сүзләрнең тамырын шартлы билге белән күрсәтегез. **(3 балл)**

**Алланып, алына, ал - тамыр**

5. “Нәрсә ул матурлык?” темасына 7-8 җөмләдән торган инша языгыз. (**8 балл**)